**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы №25 16.04.2021

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясеннән узучы, «Мәлбагыш» һәм «Мәллә» елгаларының исемнәрен үзгәртү.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында географик объектларның исеме өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, тарихи исемнәрне саклау, максатыннан, 2021 елның 22 мартында узган «Мәлбагыш» һәм «Мәллә "елгалары исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә авыл җирлеге халкының фикерен белдереп,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте :

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм чикләрендә уза торган «Мәлбагыш» һәм «Мәллә» елгалары исемен үзгәртү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыгарга .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakaevo. tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Й.Әхмәтшин